2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авылы җирлеге Югары Мактама авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2 декабрь 2023 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл җирлегенең Югары Мактама авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл җирлеге Югары Мактама авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 85 яшьтән өлкәнрәклcodeрдән тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: су белән тәэмин итү системасын, су башняларын, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итә торган скважиналарны һәм башка инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү өчен түләү; торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Югары Мактама авылы, Октябрь урамы, 50 нче йорт, территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Мактама авыл җирлеге башлыгы Н.Т. Нуриев